

Ковылкино һәм анын борынгы кардәше Наровчат шәһәре - vз тарихында озак еллар я Пенза губернасына, я Мордовиягә кереп, бер тvбә астында булганнар. Бvген икесе ике олкәгә керәләр.
Уртак тарих, мәдәният һәм сәнгать белән тыгыз бәйләнгән, бер-берсеннән 25 километр ераклыкта булган бvгенге Ковылкино һәм Наровчат хәзер ике тобәккә карыйлар.
Узган 2020 елда Россиянен ике то-бәге: Мордовия Республикасы һәм Пенза олкәсе ике боек якташыбызнын-Кочелай авылыннан халык рәссамы Федот Сычковнын һәм Наровчаттан «Поединок», «Гранатовый браслет», «Олеся» әсәрләренен авторы, рус язучысы Александр Купринннын тормыш һәм ижатларынын 150-еллык юбилей даталарын билгеләп vттеләр.

Пензанын олкәсен таныткан, туган якны ойрәнvче буларак танылган Наровчат музей комплексы директоры Александр Сохряков, сәгатьләр буе гид булырга һәм борынгы уникаль табылдыклар турында сойләргә әзер. Кvптән тvгел ул Федот Сычковнын «Крестьянская девушка» дигән уникаль картинасына ия булган. Анын оригиналы Канададан килгән. Юбилей алдыннан авыл тормышын, авыл уеннарын сурәтләргә, мукшы хатын-кызларынын шат йозләрен язарга яратучы танылган рәссамнын картинасын, мордва тамырлары булган бизнесмен Виталий Контишев, Пензадагы тарих һәм этнография музеена бvләк иткән. Бу рәсем музейнын vзәгендә урнашкан; торле яктан кvзгә кvренеп тора һәм ана игътибар итми булмый.
Үз чиратында, танылган якташыбыз, боек рәссам, кече Ватаны Ковылкино районынын Кочелаево авылы булган Федот Сычков ижаты турында югары бәя биреп, Александр Сохряков жирле музейга Наровчат белән Наровчат районы турындагы оч китапны бvләк

иткән.